**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“27” декабрь 2021 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнәавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнәавыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнәавыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яңа Әтнә торак пунктында Советская,Молодежная,Садовая,Новая,Дуслык урамнары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне чистарту, бура материалларын һәм чүп-чарны каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр илтү);
2) Балалар мәйданчыгын демонтажлау һәм башка урынга күчерү, территориясен төзекләндерү;
3) Билгеләре булган ясалма тигезсезлекләр урнаштыру

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә авылында яшәүче халык җыененың әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе вазифаларын
вакытлыча башкаручы: Самигуллин Л.А.